**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ КУТЕМИНСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

ул. Клубная, д. 1а, с. Кутема,
Черемшанский район, 423112

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**КУТӘМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

Клуб урамы, 1- нче «а» йорт, Кутәмә
авылы,
Чирмешән районы, 423112

тел./факс +8(84396) 4-30-88
email:Kut.Cmn2@tatar.ru

№ 139 20 сентябрь 2019 ел

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КҮТӘМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ КАРАРЫ

**Күтәмә авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләү турында**

2002 елның 12 июнендәге 67 – ФЗ номерлы «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22,56 статьялары, "Җирле референдум турында" 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Күтәмә авыл җирлеге Уставы нигезендә, Күтәмә авыл җирлеге Башкарма комитетының 2009 елның 20 сентябрендә кабул ителгән 138 номерлы «Референдум үткәрү инициативасы турында» карарын карап тикшергәннән соң Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Күтәмә авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. 2019 елның 17 ноябренә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.
2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләләрне расларга:

«2.1. Килешәсезме 2020 елда көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүче гражданнар, 1 төркем инвалидлардан тыш Күтәмә авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 600 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару буенча юнәлтү турында:

- Күтәмә торак пунктында урам утларын монтажлау, урнаштыру, ремонтлау, карап тоту һәм хезмәт күрсәтү, кулланылган электр энергиясе чыгымнарын түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу (хезмәтләр күрсәтү);
- Күтәмә торак пунктында җәй һәм кыш айларында җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерүгә, карап тотуга, хезмәт күрсәтүгә чыгымнар (юл кырыйларын чабуга, юлларны грейдлаштыруга, урамнарны кышкы чорда кардан чистартуга, ягулык-майлау материаллары

сатып алуга, запас частьләр сатып алуга), югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару өчен кирәкле материаллар сатып алуга (хезмәтләр күрсәтүгә);

- Күтәмә авылы зиратын төзекләндерү һәм зират янындагы йортны ремонтлау, проект-смета документлары өчен түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу (хезмәтләр күрсәтү);

- Күтәмә торак пунктында чүп үләнен чабу өчен МТЗ 80 өчен ротор чапкыч сатып алу;

- Күтәмә торак пунктында җәмәгать киңлекләрен төзекләндерү, проект-смета документлары өчен түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу (хезмәтләр күрсәтү);

3. Әлеге карарны "Безнең Чирмешән" район газетасында ("Наш Черемшан") бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталына (pravo.tatarstan.ru) Интернет мәгълүмати телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Күтәмә авыл җирлеге Башлыгы, Совет рәисе А. Н. Аброськина